**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**« БӘТКЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»**
**МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ СОВЕТЫ**

# КАРАР

«06» август 2024 ел № 9/3

« Бәтке авыл җирлегендә бюджет төзелеше һәм бюджет процессы турында» Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Биклән авыл җирлеге Советының 2019 елның 6 декабрендәге 11/3 номерлы карарына (20.04.2021 ел үзгәрешләре белән) үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1 һәм 56 статьялары, «Россия Федерациясе Бюджет кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү һәм 2022 елда Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларын үтәү үзенчәлекләрен билгеләү турында» 2021 елның 29 ноябрендәге 384-ФЗ номерлы Федераль закон (2023 елның 4 августындагы үзгәрешләр белән) нигезендә Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Бәтке авыл җирлеге Советы

КАРАР БИРДЕ:

1. « Бәтке авыл җирлегендә бюджет төзелеше һәм бюджет процессы турында» Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Бәтке авыл җирлеге Советының 2019 елның 6 декабрендәге 11/3 номерлы карарына (20.04.2021 ел үзгәрешләре белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 14 статьяның дүртенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Бюджет проектларын төзү түбәндегеләргә нигезләнә:

- Россия Федерациясе Федераль Җыенына Россия Федерациясе Президенты мөрәҗәгатенең Россия Федерациясендә бюджет сәясәтен (бюджет сәясәте таләпләрен) билгеләүче нигезләмәләре;

- Россия Федерациясенең милли үсеш максатларын һәм аларга ирешү буенча иҗтимагый хакимият органнары эшчәнлегенең юнәлешләрен билгеләүче документлар;

- Россия Федерациясенең бюджет, салым һәм таможня-тариф сәясәтенең төп юнәлешләре (Россия Федерациясе субъектларының бюджет һәм салым сәясәтенең төп юнәлешләре, муниципаль берәмлекләрнең бюджет һәм салым сәясәтенең төп

юнәлешләре);

- социаль-икътисади үсеш фаразлары;

- озак вакытлы чорга бюджет фаразы (бюджет фаразы проекты, бюджет фаразы үзгәрешләре проекты);

- дәүләт (муниципаль) программаларында (дәүләт (муниципаль) программалары проектларында, күрсәтелгән программаларга үзгәрешләр проектларында).».

1.2. 31 статьяның уникенче абзацы үз көчен югалтты.

1.3. 33 статьяның тугызынчы абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«- авыл җирлеге бюджетыннан һәм муниципаль контрактлардан средстволар бирү турында шартнамәләрне (килешүләрне) үтәү максатларында төзелгән шартнамәләр (килешүләр) буенча башкаручылар (товар китерүчеләр, подрядчылар)».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында һәм«Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам

ТР Тукай муниципаль районы
Бәтке авыл җирлеге Башлыгы, Совет Рәисе В.А.Валиева